Филологическая секция «Освещение проблемы терроризма в русской и татарской литературе»

Исследовательская работа на тему:

# Татар балалар әдәбиятының террорчылыкны кисәтүдәге роле

**Габидуллин Инсаф**

ГБОУ «Чистопольская кадетская школа-интернат имени Героя Советского Союза Кузьмина С.Е.», 6 Б класс, г. Чистополь

**Руководитель**: Аминова Гюзель Азатовна
учитель родного (татарского) языка и литературы
первой квалификационной категории

г. Набережные Челны, 2022 год

Эчтәлек

1. Кереш.........................................................................................................3
2. Төп өлеш. Террорчылыкны һәм экстремизмны кисәтүдә әдәбиятның роле.
   1нче бүлек. Нәрсә ул террорчылык һәм экстремизм?.....................5
   2нче булек. Татар балалар әдәбиятында гомумкешелек сыйфатлары.
   2.1. Толерантлык, дуслык, халыклар дуслыгын тәрбияләүче әсәрләр...........................................................................7
   2.2. Туган илгә мәхәббәт туындагы әсәрләр..............................11
   2.3. Шигырьләрдә батырлык темасы.........................................12
3. Йомгаклау.........................................................................................14
   Әдәбият исемлеге..............................................................................15

**Кереш.**

**Тикшеренүнең актуальлеге**. Хәзерге вакытта террорчылык проблемасы бөтен дөньяның иң мөһим проблемасына әверелде, чөнки гади кешеләр арасыннан күп санлы гаепсез корбаннар була, террористик актлар милли төркемнәр арасында бер-берсенә ышанмау хисен ныгыта, мәдәни һәм матди кыйммәтлекләр җимерелә, кешеләргә үлем куркынычы яный. Моңа каршы торыр өчен, кешедә кечкенәдән башлап, гомумкешелек сыйфатлары формалашырга тиеш. Әдәбият безгә дөньяны танып белергә ярдәм итә. Террорчылыкка каршы торуда, аны кисәтүдә кайсы әдәби әсәрләр һәм ничек ярдәм итә алалар?

**Тикшеренүнең проблемасы.** Террорчылыкка каршы торуда әдәбиятның роле.

**Теманы формалаштыру.** Татар балалар әдәбиятының террорчылыкны һәм экстремизмны кисәтүдәге роле.

**Тикшеренү эшенең максаты.** Террорчылыкка каршы торырга ярдәм итүче сыйфатлар тәрбияли торган шигырьләрне билгеләргә.

Күрсәтелгән максаттан чыгып түбәндәге **бурычлар** куелды:

1) Террорчылыкның һәм экстремизмның нәрсә икәнен белешергә.
2) Татар шигъриятенең террорчылыкка һәм экстремизмга каршы торудагы әһәмиятен билгеләргә.
3) Толерантлык, дуслык, Туган илгә мәхәббәт, батырлык темаларын яктырткан әсәрләрне анализларга.
4) Тикшеренү эшенә нәтиҗәләр ясарга.

**Тикшеренү объекты**. Татар шагыйрьләренең әсәрләре.

**Гипотеза**. Кешедәге кыюлык, ярдәмчеллек, дуслык, эшчәнлек сыйфатлары, үз иленең тарихы, казанышлары белән горурлану террорчылыкка каршы торырга, аны кисәтергә ярдәм итә. Шул сыйфатларны формалаштыруда татар әдәбиятының роле зур.

**Тикшеренү методлары**. Материалны өйрәнү, анализ, гомумиләштерү.

**Практик әһәмият**. Тикшеренү эшемнең нәтиҗәләрен класс сәгатьләрендә, дәрестән тыш чараларда кулланырга мөмкин.

**Фәнни – тикшеренү эшнең структурасы** кереш, төп өлеш, йомгаклау, әдәбият исемлегеннән тора.

## 2. Төп өлеш. Террорчылыкны һәм экстремизмны кисәтүдә әдәбиятның роле.

### 1нче бүлек. Нәрсә ул террорчылык һәм экстремизм?

Бүгенге көннең төп куркынычы булып халыкара террорчылык тора. “Террорчылык” сүзен бөтен илләрдә, бөтен халыклар да белә. Ул барлык кешедә дә курку хисе уята. Чөнки террорчылар самолетларны кулга төшерәләр, янгыннар, шартлатулар оештыралар, кешеләрне тоткыннар итеп алалар, күпләп юкка чыгару матдәләрен кулланалар. Террорчылар кешеләргә карата бик кырыс һәм кешелексез эшләр кылалар. Террорчыларның явыз гамәлләреннән хәрбиләр генә түгел, ә гади тыныч халык та, балалар, картлар да зыян күрәләр. Террорчылык илебезнең, җәмгыятебезнең тынычлыгына янап тора. Шуңа күрә аңа каршы тору, аны булдырмау өчен яшь буыннарда, бөтен кешеләрдә кыюлык, батырлык, эшчәнлек, ярдәмчеллек, толерантлык сыйфатларын, бер-береңне хөрмәт итү, дуслык хисен тәрбияләргә кирәк дип уйлыйм. Кешеләр Ватаныбызның казанышларын, тарихын белергә һәм аның белән горурланырга тиешләр. Минем фикеремчә, бу максатка ирешүдә әдәбиятның роле зур.

Россия Федерациясенең Федераль Законы буенча (2006 елның 6 мартындагы №53 ФЗ) “Террорчылыкка каршы тору турында”гы билгеләмәсе буенча “терроризм- халыкны куркыту яки башка законсыз тәэсир итү юллары белән бәйле көч куллану идеологиясе һәм җәмгыять аңына тәэсир итү практикасы, дәүләт власте органнарының карар кабул итүләренә тәэсир итү, җирлек үзидарә итү органнарының яки халыкара оешмаларнның карар кабул итүләренә тәэсир итү.

Террористик акт – халыкны куркыта торган һәм кешегә үлем куркынычы яный торган, милеккә зур зыян китерергә мөмкин, власть органнарының яки халыкара оешмаларның карар кабул итүләренә тәэсир итү максаты белән шартлату, янгын һәм башка гамәлләр.

Террорчылыкның төп сыйфатлары: 1) максаты – власть органнырының карар кабул итүләренә тәэсир итү; 2) юлы – җәмгыять аңына тәэсир итү; 3)

тәэсир итү чаралары - көч куллану, халыкны куркыту, законсыз тәэсир итү юллары.

Террорчылыкның барлыкка килү сәбәпләрен 5 төркемгә бүлеп була: сәяси, социаль-икътисади, икътисади, дини, рухи. Сәяси тотрыксызлык, яшәү дәрәҗәсе түбән, бизнес, сугыш кораллары, наркотиклар белән сәүдә итү, хокукый һәм гомумкешелек нормаларын бозу.

Террорчылык - экстремизмның аерылгысыз өлеше, аның бер күренеше. Экстремизм - тегe яки бу милли, дини, мәдәни карашлары бер төрле булган кешеләрнең үз идеяләрен гадәттән тыш өстен итеп тоюлары, тормышларын ахыргача шул идеяләрне чынга ашыруга багышлау һәм дөньяда башка төрле карашлар да булу мөмкинлеген танымау, кире кагу, сайлаган максатларына ирешү өчен чиктән тыш, кайчакларда көчләү чараларын да куллану.

Кагыйдә буларак, экстремистик эшчәнлек түбәндәге формаларда тормышка ашырыла:

- тегe яки бу дини, милли, раса һәм социаль төркемгә карата тискәре караш сеңдерү яисә аларга каршы көчләү гамәлләре куллану белән бәйле әзерлеккә чакыру;
- милли хисне кимсетү, тегe яки бу милләт вәкилен кыерсыта торган мәгълүмат тарату, аларда бу халыкның казанышлары кимсетелә яисә аның генетик яки тарихи артталыгы күрсәтелә;
- гражданнарның дингә мөнәсәбәтенә, социаль хәленә, расасына, милләтенә, диненә яки теленә сүз тидерү, башлыча, үзләренең өстенлекләрен, башка төркемнәрнең мескенлеген, үсештәге артталыкны җиңәргә сәләтсез булуларын күрсәтергә тырышу;
- идеология, сәясәт, раса, милли яки дини дошманлык мотивлары буенча массакүләм тәртипсезлекләр, хулиганлык, вандализм күренешләре китереп чыгару.

Массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендә, митинг һәм җыелышларда югарыда әйтелгән гамәлләрне тормышка ашырырга чакырган эшчәнлек яки андый эшчәнлекне финанслау да экстремизмга керә.

## 2нче булек. Татар балалар шигъриятендә гомумкешелек сыйфатлары.

### 2.1. Толерантлык, дуслык, халыклар дуслыгын тәрбияләүче әсәрләр.

Террорчылык һәм экстремизм агрессиядән башлана. Агрессиянең килеп чыгуын кисәтү юлында әдәбият тора. Чөнки әдәби әсәрләр, дөньяның, туган илнең матурлыгын, төрлелеген, дуслыкның кыйммәтен, батырлыкның үрнәкләрен күрсәтеп, кешене әхлакый тәрбияләүдә ярдәм итәләр, кеше тормышын кадерләргә, хөрмәт итәргә өйрәтәләр.

Бер милләт вәкиленең икенчесенә карата булган түземлелек (толерантлык) хисләрен тәрбияләүдә татар балалар шигъриятенең әһәмияте зур. Юкка гына халкыбыз: “Кош канаты белән, кеше дуслык белән көчле”, димәгән. Татар һәм рус халыкларының дуслыгы турында күп кенә әсәрләр язылган. Мәсәлән, Бари Рәхмәтнең “Әби белән бабушка” шигырен алыйк.

Ике карчык гөрләшәләр тышта,
Берсе – әби, берсе – бабушка,
Берсе – оек, берсе чулок тоткан,
Икесе дә оста бик эштә.

Дуслар да бик: пирог пешкән көнне
Әбине дә дәшә бабушка,
Бәлеш пешкән көнне бабушканы
Дәшми калмый әби бәлешкә.

Белгән сүзен русча, белмәгәнен
Үз телендә әби сукалый,
Ә бабушка, аңлаган кук аны,
Башын селки, күзен кыскалый.

Әби көлсә, улда көлгән була
Белмәсә дә нигә көлгәнен,
Күгәрчен кук гөрли-гөрли шулай
Уздыралар бергә көннәрен.

Бу шигырьдә автор, ике әбинең төрле милләт кешеләре булуына карамастан, бик дус яшәүләрен күрсәтә. Алар тату гына “гөрләшәләр”, икесе дә бик осталар, бер-берсен кунакка чакыралар, “уздыралар бергә көннәрен”, русча яки татарча сүзләрне белмәгәндә, үз телләрендә әйтәләр һәм аңлаган кебек баш селкиләр. Димәк, аларда тел проблемасы юк, бер-берсен әйбәт кабул итәләр. Аларның тормышлары, аралашуы бөтен кешеләр өчен үрнәк булып тора.

Ш.Галиевнең “Дуслык балы” шигырендә татар һәм башкорт кешеләре дуслыгы, бер-берсен аңлашулары турында язылган. Бу җирдә янәшә торып, бал кортларына “гөл илендә” “чикләр юк”,” бикләр юк”, берсенең балкорты белән чәчәге күптән кушылган. Шул бал кортлары кебек кешеләр дә бер-берсен мактап, уртак җыр җырлап, “туганнарча” кунакка йөреп яшиләр.

Дустым миңа алып килгән
Күчтәнәчкә «Башкорт балы»,
Янәшәгә мин дә куям —
Җыйган татар бал кортлары.

Кысташабыз алмаш-тилмәш,
Макташабыз алмаш-тилмәш,
Очрашабыз алмаш-тилмәш —
Бик күңелле дустың килгәч!

Син дип, мин дип бүлешергә
Гөл илендә чикләр юк бит,
Касәләре көнгә ачык,
Гел дә ачык — бикләр юк бит.

Синең балкорт, минем чәчәк
Күптән инде кушылгандыр,
Синең көйме, минем җырмы —
Җан уртаклык шушындадыр?

«Сезнең бал шәп!», «Сезнеке!» — дип,
Макташыйк без бергә килеп,

Туганнарча йөрик шулай,

Сезгә барып, безгә килеп.

Р.Миңнуллин “Бөтендөнья балалары, берләшегез!” шигырендә Татарстан балалары исеменнән бөтен дөньядагы балаларны берләшүгә, дус булырга һәм дус булып калырга өнди, чөнки “без яшибез бер үк җирдә“, “без - кешеләр”, ди.

Үскәчтен дә

Дошман булмыйк

Беребез дә.

“Дуслык!” сүзе

Булсын безнең

Телебездә!

Шулай бер-беребезгә тынычлык теләп яшәсәк, “килер безгә гомумбәхет дәвере”. Бомбалар урынына самолетлар чәчәк чәчәр”, “кешеләр бер гаиләдәй гөрләп яшәр”, дигән фикер туа.

Шул ук авторның “Мин җырларга яратам!” шигырендә дөньяның матурлыгы, Туган илне зурлау, ярату, дуслык турында яза. Димәк, балалар, җирдә Туган илне яратып, кешене хөрмәт итеп яшәү рәхәт була, дигән нәтиҗә ясыйлар.

Җырларымда Туган илне,

Туган җирне зурлыйм мин.

Без бу җирдә дус һәм туган –

Рәхәтләнеп җырлыйм мин!

Рус малае, татар кызы –

Дусларымның барчасы

Кушыла миңа...Гөр килә

Безнең дуслык бакчасы!

“Малайлар сугыша” шигырендә Р.Миңнуллин шулай ук дуслык, тынычлык проблемаларын күтәрә. Малайлар “канга батырганчы” сугышалар, ләкин көчсезрәк малайга сукканчы “көчеңне башкача була бит сынарга”, ди

автор. “Бернинди сәбәпсез рәнҗетү кешене, сугышу, кыйнашу” егетләр эше түгел. Бөтен җирдә, бөтен кешегә тынычлык кирәк, ә ул “дуслыктан башлана”. “Без көчле - үзара тик дуслык булганда”. Шуны аңлаган кеше башкаларга зарар китермәс.

Эльмира Шәрифуллинаның “Дуслык, чын дуслык!” шигыре дуслыкның көче бергә булуда, бердәм булуда икәнен күрсәтә. Дуслык, дөрестән дә, зур кыйммәт.

Ярдәмләшеп, җырлап-көлеп
Яшик кояшлы елда.
Бергә булыйк, бердәм булыйк –
Дуслыкның көче шунда.

Экстремизмга һәм террорчылыкка каршы көрәшүдә татар әдәбиятының роле зур. Татар әдипләре кешенең әхлакый сыйфатларын тәрбияләп, үстереп, агрессиягә каршы торуда зур файда китерәләр.

## 2.2. Туган илгә мәхәббәт туындагы әсәрләр.

Туган илгә мәхәббәтне тою – үзеңне Ватаныбызның аерылгысыз өлеше итеп хис итү. Туган җиргә хөрмәт, аның белән горурлану ялганга һәм кансызлыкка каршы торырга ярдәм итә.

Хәй Вахит язган “Минем Ватаным” шигыре кешедә туган илебезнең байлыклары, матурлыгы, уңышлары белән соклану һәм горурлану хисен уята. Туган җирен яраткан кеше аңа һәм халкына зыян китермәс.

Туган илем нинди киң!
Нинди матур Ватаным!
Балкуыннан ал таңның
Киңлегенә нур алган.
Чиксез басу, саф күлләр,
Хәтфә болын, кыр чүлләр
Яшеллекә уралган.

Р.Миңнуллин “Кунакка килегез!” шигырендә туган җиребезгә-Татарстаныбыызга дан җырлый.

Безнең якларны күрсәгез,
Сез шаккатыр идегез.
Дусларыгыз көтә сезне -
Татарстанга килегез!

Автор “җирнең иң матур җирендә – Татарстанда” яшим, ди. Ул, кунакка килгән кешеләргә, туган җиребезнең бөтен матурлыгын курсәтергә җыена.

## 2.3. Шигырьләрдә батырлык темасы .

Халкыбызның тарихын, мәдәниятен белү башка халыкларның тарихына һәм мәдәниятенә карата ихтирамлы мөнәсәбәттә булырга булыша. Шуңа күрә Туган илебезнең бай тарихын белергә дә, истәлекләрне сакларга кирәк.

Гәрәй Рәхим “Ветераннар” дигән шигырендә Бөек Ватан сугышы ветераннарына батырлык күрсәткән өчен, азатлык, җиңү китергән өчен рәхмәтле булырга, аларга карата ихтирамлы булырга кирәлеген сиздерә, сугыш кырларындагы батырлыклары белән горурлана.

Картаймагыз әле, ветераннар,
Ауропаны саклап калган ирләр;
Хәтерлиләр, сезне данлы юллар,
Хәтерлиләр, сезне азат; илләр.

Илләр, җырлый бәйрәм, көннәрендә
Сезнең яшьлек — җиңу көйләрендә.
Сез аларга ирек китердегез,
Шатлык китердегез өйләренә.

Картаймагыз әле, ветераннар,
Илгә дан китергән тынмас җаннар.
Сезгә тиеш әле бик күп назлар,
Сезгә тиеш әле бик күп язлар

Батырлык темасын Р.Миңнуллин да үз әсәрләрендә күтәрә.

“Батыр булыгыз”

Батырлыкны эшли ала
Бөтен кеше дә.
Аның өчен кирәк түгел
Алып көче дә.
Яратырга кирәк бары
Туган җиреңне,

Әтиеңне-әниеңне, туган илеңне!

Батыр кеше туган илен ярата, аның тынычлыгы өчен үзен кызганмый.

“Тынычлыкның туган көне” шигырендә

Борчылмагыз! Үсеп килә

Батырларның

Оныклары.

Бабайларның батырлыгын

Бер малай да онытмады!

Буыннар бәйләнеше, бабаларыбызның батырлыгы мәңге хәтердә сакланырга тиешлеге турнырда бу шигырь.

“Саклап калыйк җирне!”, “Яшәү рәхәт түгелмени?”, “Әкияттә генә”, “Бер бомба да калдырмас иде” һәм башка шигырьләрдә тынычлыкның кадерен, яшәү кыйммәтен белергә, сугышны башламаска, сугышсыз яшәргә өндәү яңгырый.

**Йомгаклау.**

Тикшеренү эшенең төп мәсьәләсе террорчылыкка каршы торуда һәм аны кисәтүдә тәрбияви әһәмияткә ия булган әсәрләрне өйрәнү һәм билгеләү иде. Үткәргән тикшерүдән чыгып, мондый нәтиҗәләр ясарга мөмкин:

- экстремизм һәм терроризм - бөтен кешелек дөньясына каршы юнәлгән җинаятьчелек;
- экстремизмны һәм террорчылыкны кисәтү юлында әдәбият зур роль уйный;
- әдәби әсәрләр кечкенәдән кешедә әхлакый сыйфатлар формалаштыра;
- Р.Миңнуллин, Х.Вахит, Б.Рәхмәт, Ш.Галиев, Э.Шәрифуллина, Г.Рәхим әсәрләрен террорчылыкка каршы торырга ярдәм итүче сыйфатлар тәрбиялиләр.

Минем гипотезам расланды дип уйлыйм: кешедәге кыюлык, ярдәмчеллек, дуслык, эшчәнлек сыйфатларын, үз иленең тарихы, казанышлары белән горурлануны формалаштырган татар әдәбияты әсәрләре террорчылыкка каршы торырга, аны кисәтергә ярдәм итәләр, тыныч,имин тормыш урнаштыруның бер ысулы булып торалар. Тикшеренү эшемнең нәтиҗәләрен дәрестән тыш чараларда, сыйныф сәгатьләрендә кулланырга мөмкин.

**Әдәбият исемлеге.**

1. Р.Миңнуллин. Сайланма әсәрләр. 1 китап.- Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2004, 67б.
2. Р.Миңнуллин. Сайланма әсәрләр. 2 китап.- Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2004, 62б, 68б, 70б, 195б, 198б, 271б.
3. Молодежь и антитеррор: учебное пособие/А.Г.Караваев – Москва, 2013, стр.4.
4. Электрон ресурслар:
   http://tulachi.ru/news/yazmalar/terrorizmnyi-kist-rkemnn-uyaulyik-sorala
   https://intertat.tatar/news/sugysh-turynda-shigyrl-r